Республика Татарстан
Глава Бизякинского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423648, село Бизяки,
ул. Центральная. 46

Татарстан Республикасы
Менделеевск
муниципаль районы
Бәзәкә авыл жирлеге
башкарма комитеты
423648, Бәзәкә авылы,
Узәк урам, 46

Тел./факс 3-47-34

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

5.12.2022 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 14 декабре 17.00 сәгатьтә Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.2022 елның 15 декабре 10.00 сәгатьтә Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

* 3. 2022 елның 15 декабре 16.00 сәгатьтә Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Бәзәкә авыл җирлеге җыеннарының барлык этапларын түбәндәге адреслар буенча үткәрү урыны:

Беренче этап: Бәзәкә авылы Яңа урам, 1нче йорт авыл мәдәният йорты
Икенче этап: Бәзәкә авылы Үзәк урам 46 й. административ бина
Өченче этап: Бәзәкә авылы, Яр буе урамы

5. Бәзәкә авылы халкы исемлеген җыеннар этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Яшьләр урамы 1 нче йорттан 126 й. кадәр , Елга аръягы ур., 1 йорттан 106 йортка кадәр, Яңа урам 1өорттан 36 йортка кадәр

Икенче этап: Үзәк урам, 1-102 номерлы йорттлар

Өченче этап: Яр буе урамы 1 нче йорттан 36 нчы йортка кадәр .
Дуслык урамы 1 нче йорттан 14 нче йортка кадәр, Бакча урамы 1 нче йорттан 11 нче йортка кадәр.
Рифкать Таҗиев урамы 4,7 нче йорт; Урман урамы 10 йорт

6.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә 1 һәм 2 төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, балигъ булмаган күп балалаы гаиләләрдән, көндезге (көндезге) уку формасы студентларыннан, Россия Армиясенә хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереп, түбәндәге эшләрне башкаруга сез ризамы

- Бәзәкә авылының Үзәк урамы буенча асфальтны ремонтлау;
- «Сабантуй» бәйрәменә сәхнә ясау өчен материал алу (такталар, брус);
- кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
- вак таш сатып алу һәм китерү;
- вак таш тутыру буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү
- Балалар, спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, балалар, спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү;

төяү насослары сатып алу

скважина өчен торбалар сатып алу

- Үлән чаптыру буенча транспорт хезмәтләре

санкцияләнмәгән чүп-чарларны бетерү буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү

- Урам яктырткычларын сатып алу;
- Яктылык баганаларын урнаштыру, урамнарны яктырту җайланмалары.
- Янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр алу
- суүткәргеч торбаларына кирәк=яраклар алу.
- Узган елларның калдыкларын юлларны кардан чистартуга юнәлдерергә

« РИЗА» "КАРШЫ"

7. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә - www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында - pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы:
И.И. Кәшәфетдинов